ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 24 декабрендә
кабул ителде

## 1 статья

«Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау хакында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 7 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 7; 2014, № 6 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш); 2024, № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән затлар.»;

2) 3 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында «35 кешедән алып» сүзләрен «36 кешедән алып» сүзләренә алмаштырырга.

## 2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 26 декабрь
№ 94-ТРЗ